СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

29.09.2017　　　　с. Печищи　　　　№ 24-111

Печищи авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п. нигезендә, Печищи авыл җирлеге Уставының 11 ст., Печищи авыл җирлеге Советының 25.09.2017 ел, № 23-107 «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Печищи авыл җирлеге башлыгының 25.09.2017 ел, № 6 «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Печищи авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2018 елда үзара салым кертүгә Печищи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешерсезме:

- Су белән тәэмин итү системасын һәм су белән тәэмин итү объектларын ремонтлау һәм реконструкцияләү

ӘЙЕ　　　　　　　　　　ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары

Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Печищи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы А.С. Шамсутдинов